Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең
Колшәрипторак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

30 ноябрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының35 статьясы, 2021елның 25 ноябрендә 17 сәгать00 минутта, 2021елның 26ноябрендә11 сәгать 00 минутта, 2021 елның 26 ноябрендә 12 сәгать00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә13 сәгать00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә14 сәгать00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә15 сәгать00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә16 сәгать00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге:«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге Колшәрип авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме юлларны, урам утларын, су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү, җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1452 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 822 кеше, бу 56,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 813«РИЗА»позициясе өчен тавыш бирде; гражданнар җыенында катнашучыларның 9«КАРШЫ»позициясе өчен тавыш бирде..

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең Колшәрипторак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыКолшәрип авыл җирлегенең Колшәрип авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче булган һәр балигъ булган кешедән үзара салым средстволарын 2022елда 500 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрнебашкаруга юнәлдерергә:юлларны, урам утларын, су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү, сметалар төзү, техник күзәтү үткәрү, җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

4.Әлеге карарны«Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Колшәрипавылы, Тукай урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматларрәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты«Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыены ндарәислекитүче А.Ф. Кашафутдинов